# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 6 1 ноябрь 2022 ел.

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Пионер бистәсендә үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 12 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Пионер п., Үзәк ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан Пионер авыл клубында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Пионер бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыелышын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Пионер бистәсе торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту ,килешү буенча эш өчен түләү)
- Пионер бистәсе торак пунктында юлларга вак таш сатып алу
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Пионер бистәсе скважинасы өчен генератор сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә халык күпләп җыела торган урыннарда, белдерү такталарында һәм стендларда элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.
3. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ